**ГЛАВНОЕ<br>АРХИВНОЕ УПРАВЛЕНИЕ<br>ПРИ КАБИНЕТЕ МИНИСТРОВ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН<br>(ТАТГЛАВАРХИВ)**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ<br>КАРШЫНДАГЫ<br>БАШ АРХИВ ИДАРӘСЕ<br>(ТАТБАШАРХИВ)**

# БОЕРЫК

29.07.2015 Казан № 055

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсенең «Татарстан Республикасы дәүләт архивларының эшкуарлык эшчәнлеге турында нигезләмәне раслау хакында» 2009 елның 19 маендагы 015 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы дәүләт архивларының түләүле нигездә эшләр башкаруы (хезмәтләр күрсәтүе) нәтиҗәлелеген арттыру максатларында

боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсенең «Татарстан Республикасы дәүләт архивларының эшкуарлык эшчәнлеге турында нигезләмәне раслау хакында» 2009 елның 19 маендагы 015 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт архивларының эшкуарлык эшчәнлеге турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2. Түләүле нигездә эшләр башкарудан (хезмәтләр күрсәтүдән) алынган керемнең гомуми суммасыннан 40% алып 60% кадәре архивлар хезмәткәрләренә премияләр түләүгә җибәрелә.

Керемнең калган өлеше табышны тәшкил итә һәм ул җиһазлар сатып алуга, матди-техник базаны карап торуга һәм үстерүгә, ремонт эшләре өчен түләүгә; матди ярдәм күрсәтүгә (юбилейлар, ветераннарга хөрмәт күрсәтү, күмүләр), хезмәт күрсәтүче персоналга премияләргә, хезмәт хакы түләүгә, авторлык түләүләрен башкаруга, «Гасырлар авазы – Эхо веков» фәнни-документаль журналын һәм аңа кушымталарны әзерләүдә катнашкан өчен штаттан тыш хезмәткәрләрнең һәм Идарә хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүгә; Идарәнең 2015 елның 29 июлендәге 054.1 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булып тормаган вазыйфаларны биләүче һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсене техник тәэмин итүне һәм аның эшчәнлегенә хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы хезмәткәрләргә еллык түләүле отпуск биргәндә бер тапкыр түләнә торган түләүне башкару тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәдә каралган тәртип нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булып тормаган вазыйфаларны биләүче һәм Идарәне техник тәэмин итүне һәм аның эшчәнлегенә хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы

хезмәткәрләргә еллык түләүле отпуск биргәндә ике вазыйфа оклады зурлыгында бер тапкыр бирелә торган түләү башкаруга, хәйрия ярдәме күрсәтүгә тотыла.».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсенең хокук һәм кадрлар эше бүлеге башлыгы В.Г. Минниәхмәтовага әлеге боерыкны дәүләт теркәве уздыру өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Башлык Д.И. Ибраһимов